КӨТӘЛӘР ҺӘМ ӨМЕТЛӘНӘЛӘР
Мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләре аерым игътибарга лаек
> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ
Хатларда – укучыларыбыз уй-фикерләре
> 4

БАЛАЛАР ХАКЫНА!
«ВТ» хәбәрчесе Царево бистәсе ата-аналарының зарын тыңлады
> 5


ХА-ХА-ХАНӘ
Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 175 (28948) | Шимбә | 26 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«БӘХЕТЕМ – ҮСТЕРГӘН УЛЛАРЫМДА»

27 ноябрь – Әниләр көне

Хатын-кызның бәхете – гаилә бөтенлегендә, балаларда, ә гаилә бәхете – хатын-кыз кулында. Бу кулларда бетмәс-төкәнмәс көндәлек мәшәкатьләр, эш барлыгын да искә төшерсәң, күтәрә алмаслык йөк кебек. Тик Апас районының Әҗем авылында яшәүче Динә Вилданова өчен түгел. Өйдә ул – яраткан хатын, әни, дәү әни, ә капканың теге ягында – Динә Хәйдәровна. Әниләрнең көче нидә?

Беренче карашка, Вилдановлар гап-гади бер гаилә кебек. Тик аларның бер-берсенә мөнәсәбәтендә, фикер йөртүләрендә үзара хөрмәт ярылып ята. Өч ир бала тәрбияләп үстергән әни моның сере белән уртаклашты. «Гаилә бәхете хатын-кыздан тора, – ди ул. – Берәүнең дә тормышы тигез генә, шома гына бармый. Берең ут булып кызганда, икенчең су була белергә кирәк. Без яшәгән тормышны балалар өлге итеп алалар бит. Юкка гына оясында ни күрсә – очканда шул була, дип әйтмиләр».

Динә һәм Фазил Вилдановлар – бер-берсенә тиң ярлар. Шулай булмый ни, аларны уртак фамилия генә түгел, ә уртак дата да берләштерә. «Без икебез дә бер үк елны, бер үк айда, бер үк көнне туганбыз. Никах күкләрдә укыла, диләр, бу дөрестер. Шулай булмаса, икебез ике районда үскән егет белән кыз очрашып кавышмас идек. Фазил да, мин дә – авыл балалары. Ул – сигез, мин җиде балалы гаиләдә үстек. Уртак максатыбыз бар иде – кечкенәдән үз йортыбызны булдырып, күп бала үстерү турында хыялланганбыз. Шөкер, барысы да без теләгәнчә килеп чыкты. Горурлыгыбыз булырлык өч улыбыз бар. Өчесе дә эшнең ни икәнен белеп үстеләр. Алар шулай тәрбияләнгән, бер эштән дә куркып тормыйлар. Безнең гаиләдә монысы – ир-атныкы, монысы – хатын-кызныкы дигән бүленеш юк. Мин 30 ел мәгариф өлкәсендә эшләп, шуңа инандым: өйдә, гаиләдә эшләп үскән балалар ныклырак та, сәламәтрәк тә. Шуңа күрә балаларны эшләтүдән курыкмаска кирәк. Хезмәт күреп үскәннәр тормышта да югалып калмый. Мәсәлән, укудан кайткач, кар көрәп керсә, баланың башы ял итә, бу файдага гына. Тегене эшлә, моны эшлә, дип өстән фәрман биреп утыру дөрес түгел, әлбәттә, балага шәхси үрнәгең кирәк», – дип сөйли әни кеше.

Вилдановлар гаиләсендә чын үрнәк булырлык әтиләре бар. Фазил Вилданов, районда беренчеләрдән булып, 2011 елда крестьян-фермер хуҗалыгы ачып җибәргән. «Әтиләре мөгезле эре терлек асрау белән шөгыльләнгәч, балалар да терлек тирәсендә үстеләр. Алар малны карау, ашату серләрен бик яхшы беләләр. Әтиләре аларга һәрвакыт үрнәк булды», – ди Динә ханым. Сүз уңаеннан, Вилдановлар гаиләсендә армиягә бару-бармау мәсьәләсендә дә икеле-микеле сөйләшеп тормыйлар. Әтиләре улларын кечкенәдән үк, солдат хезмәте ул – чын ир-егетнең бурычы, дип төшендереп үстергән. Ике уллары армия хезмәтендә булган инде. Өченчесе әлегә кечерәк. Рамазан Борындык урта мәктәбенең 9 нчы сыйныфын тәмамлап, хәзер укуын Казан архитектура-төзелеш көллиятендә дәвам иттерә. Уртанчы уллары да – Казанда, Айдар полиция хезмәтендә эшли.

Олы уллары Инзил исә, әтисе юлыннан китеп, үзенең крестьян-фермер хуҗалыгын булдырган. «Олы улыбызның гаиләсе белән бердәм гаилә булып бер түбә астында яшибез, – ди Динә Вилданова. – «Килен белән яшәү кыен түгелме?» – дип еш сорыйлар. Андыйларга җавабым бик гади: тату яшәүнең сере – күп күрмәскә, күп ишетмәскә һәм яшьләр тормышына кысылмаска. Чынлап та, алар бар нәрсәгә яңача карый. Яшьләргә юл бирергә кирәк. Үзебез гаилә коргач та, әти-әниләр безгә тормышта ирек бирде. Өй салырга теләдек – өйле булдык, эшлисе килде – һөнәрле булдык. Һәр гаилә үз хатасында тормышка өйрәнергә тиеш дип саныйм».

Юл бирү дигәннән, ишле гаиләдә малайларга һөнәр сайлауда да ирек биргәннәр. Өлкәннәр бу эшкә гомумән катышмаган. «Аларның сайлавын хупладык кына. Чөнки һөнәр кешене гомере буе озата бара. Әти-әни әйткәнгә, туганнарның мөмкинлеге булганга гына түгел, ә үз җаныңа якын булган һөнәрне сайларга кирәк», – ди Динә Вилданова.

Балаларны тәрбияләүдә иң мөһим нәрсә – аларны ярату. Өч малай тәрбияләп үстергән әни әнә шул фикердә:

– Әйтәләр бит әле, баланы артык ярату боза, дип. Артык иркәләү, аның бөтен теләген үтәү боза баланы. Ә яратырга кирәк. Балаларым өчен мин әни генә түгел, чын дус та. Нинди генә проблемалары булса да, барысын да уртага салып сөйләшәбез. Алай гына да түгел, үземне борчыган сорауларны аларга бирәм, улларым белән киңәшәм. Улларым минем ярдәмчеләрем булдылар. Кирәк булса, ашарга да пешерәләр. Бу файдага гына. Әнә Казанга укырга чыгып киткән улым хәзер рәхәтләнеп үзенә ашарга пешерә. Алар – миннән, мин алардан өйрәнәм. Җитәкче булып эшли башлагач, бала тәрбияләргә әллә ни күп вакыт та калмагандыр, бәлки.

Динә Вилданова 2011 елдан бирле Апас районының Борнаш урта мәктәбе директоры булып эшли. «Җитәкче хатын-кыз өчен гаилә – үлчәүнең бер ягында, икенче ягында – эш. Шушы тигезлекне саклау бик зур көч сорый. Табигатем буенча – тургаймын. Җаваплы эштә булсам да, иртәнге сәгать дүрттә торып ашарга да пешерә алам, өйдәге вак эшләрне дә башкарам. Өйдә әни җылысы булырга тиеш. Ирем өчен дә, балаларым өчен дә уңайлы шартлар булдырырга тырышам. Мәктәптә – 27 хезмәткәр, 73 укучы. Аларның һәркайсының – үз проблемалары. Эшемне бик яратам. Күп еллардан соң укучыларым килеп рәхмәт әйткәч, тагын да рәхәт булып китә. Өйдә киленем Айгөл – бик зур терәгем. Ул барлык эшләрдә дә булыша. Эштән кайнар ашка кайтып керәм», – ди Динә Вилданова.

Авыл җире булгач, йорт тирәсендәге эшләр дә җитәрлек. Зарланмый Вилдановлар. Февраль аенда тәрәзә төбен тутырып кыяр-помидор үсентеләре үстерәләр, бакчада зур теплицалары бар. Ишегалдында әтиләре уллары белән бергә утырткан рәт-рәт алмагачлар үсә. Ял да итә беләләр. «Язкөз, кыр-басу эшләре беткәч, бергәләп табигатьтә шашлык пешерәбез, улларым балык тотарга ярата, – ди әни кеше. – Минем өчен әни бәхете – үстергән улларымда. Шөкер, алар турында беркайчан да начар сүз ишетмәдем. Дүрт айлык оныгым да бик якын. «Бала баласы балдан татлы», – дип юкка гына әйтмиләр икән. Эштән кайтып кергәч, иң башта оныгымны алып сөям. Өйдә сине көтеп торалар икән, иң зур бәхет шул». Оныкчыкның исеме дә – Диана. Сөйләшкәндә, исем сайлауда безнең бернинди катышыбыз юк, дип тә әйтеп куйды Динә ханым. Сүзләр артык. Балаларның әнигә булган хөрмәте әнә шуннан да күренә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Хәрби исәпкә тәртип кертелә

Россия Президенты Владимир Путин 2024 елның апреленә хәрби учет документлары буенча дәүләт мәгълүмат ресурсын булдырырга кушкан. Бу җәһәттән тиешле указ хокукый мәгълүматлар рәсми интернет-порталына урнаштырылган.

Указ нигезендә әлеге эш, Оборона министрлыгы катнашында, Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгына, Салым федераль хезмәтенә йөкләнгән.

Моңа кадәр Путин Россиядә өлешчә мобилизация үткәрүдәге буталчыклыклар турында искәртеп үткән иде. «Дистәләрчә еллар буе яңартылмаган иске учет формаларына бәйле бу. Мобилизация чаралары үткәрелә башлагач кына аларның сыйфаты ачыкланды», – диде ул.

Президент әйтүенчә, мәгълүматлар базасы максималь дәрәҗәдә дөрес булачак.

Саллы ярдәм

Татарстанда ел башыннан 18,4 мең гаилә ана капиталы ярдәмендә торак алган. Акчадан файдалану өчен тапшырылган барлык гаризаларның 65,2 проценты шуңа бәйле. 16,1 мең гаилә торак алу яки төзү өчен алынган кредитның беренче кертемен ана капиталы белән түләгән яисә кредитны өлешчә (тулысынча) шул акча хисабына каплаган. Әлеге максатка Пенсия фонды гаиләләргә 10 миллиард сум күчергән. Быел ана капиталы бирүгә юнәлтелгән барлык акчаның 95 процентын диярлек тәшкил итә бу.

Торак шартларын яхшырту өчен ана капиталын балага өч яшь тулгач тотарга мөмкин. Ипотека буенча беренче кертемне яки төп бурычны түләү очрагында, бала тууга ук акчадан файдалану рөхсәт ителә.

Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, 2020 елның апреленнән, кредитка (ипотека) торак сатып алганда, ана капиталыннан файдалану турында гаризаны турыдан-туры кредит бирүче банкка тапшырырга мөмкин. Банк гариза һәм кирәкле документларны Пенсия фондының территориаль органнарына электрон элемтә аша тапшыра. Болай эшләү капиталдан файдалануны тизләтү мөмкинлеге бирә.

2 миллионга җиткермәкчеләр

Эштә бәхетсезлек очрагы килеп чыгу сәбәпле һәлак булган яки һөнәри авырудан үлгәннәрнең гаиләләренә иминият акчасын арттыруны күздә тоткан закон проекты Дәүләт Думасында каралачак. Түләү күләмен 2 миллион сумга җиткерү тәкъдим ителә.

Документка аңлатма язуында әйтелгәнчә, иминиятләштерелгән кешенең үлүе очрагында түләү күләме әлегә 1 миллион сум тәшкил итә. Инфляциягә карамастан, акча күләме 2014 елдан бирле үзгәртелмәгән.

Шулай итеп, производствода яки һөнәри чирдән үлгәннәрнең гаиләләренә 2 миллион сум күләмендә бер тапкыр иминият түләвен билгеләү тәкъдим ителә.

«Киләчәк уеннары – 2022»

Уен алдыннан уйнап алалар

Мәгълүм булганча, Казан «Киләчәк уеннары» халыкара турнирын уздыру хокукына ия булды. Чара 2024 елның февраленә тәгаенләнгән. Моңа кадәр спортчыларга да, Казанга да мөмкинлекләрен һәм көчен сынап карыйсы. Әзерлек башланды инде. Бу көннәрдә башкала «Фиджитал уеннар» тәэсирендә яши.

gamesofuture.com

Чишмә башы

Әлегә колак һәм аң өчен ят булган сүзгә ияләшә торсак була. Гомумән, бу чаралар киң даирә өчен яңа сүзләрне күп бирәчәк. Әмма, шик юк, киберспортчылар, шушы өлкәдә кайнаучылар өчен, көтеп алынган вакыйгалардан санала бу уеннар.

Татарстанның спорт министры Владимир Леонов та, сентябрь аенда журналистлар белән очрашкач:

– Дөресен әйтик: бу әле безнең өчен дә – яңалык. Бу – киләчәккә бер адым да. Барлык инновацияләрне кулланып карарга һәм безгә ярышларны шәп итеп оештырырга да кирәк, – дигән иде.

25 ноябрьдә башланып киткән «Фиджитал уеннар» моңа кадәр сентябрь аенда узган әзерлек ярышларының дәвамы булып тора. Бу юлы спортчылар картинг (машиналар ярышы. – **Авт.**), көрәш, хоккей буенча көч сынаша. Искәртеп узыйк: гадәти ярышлардан аерыла алар. «Фиджитал уеннар» дигәндә спортның классик төрләрен һәм киберспортны берләштергән ярышларны күзалларга кирәк. Әлеге уеннар чынбарлык һәм цифрлаштыруны берләштерә, спортчылардан техник, санлы (виртуаль), физик әзерлек таләп итә. Гади генә әйткәндә, катнашучы цифрлы дөньяда да, чынбарлыкта да ярыша, уйный.

Беренче ярышлар узды инде. Спортчылар да, тамашачылар да бер фикердә – бу уеннар, чыннан да, яңалык һәм мавыктыргыч.

«Безне бик кәттә уеннар көтә икән!»

Ноябрь ярышлары 26сы төгәлләнә. Аннан спортчыларны 10–11 декабрь көннәрендә уеннар көтә.

25 ноябрьдә, «Фиджитал уеннар»ның ачылышында, спортчылар картингта көч сынашты. Уеннарны мөмкин кадәр кызыклы итеп ясарга тырышканнар. Әйтик, бу өлкәдә уңыш казанганнар белән беррәттән, блогер, спортның бүтән төрләрендә профессионал саналганнар командасы өчен аерым ярышлар уздырганнар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Вадим УВАРОВ, Россия банкының Мәгълүмат куркынычсызлыгы департаменты директоры:

Ил халкының исәп-хисап счетларыннан акча урлау очраклары моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җитте. Агымдагы елның июль – сентябрь айларында мошенниклар 4 миллиард сумга якын акчаны кулга төшергән. Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда әлеге күрсәткеч 23 процентка арткан. Гомумән алганда, илнең финанс-кредит системасы киберһөҗүмнәргә уңышлы каршы тора.

(«Парламентская газета»га әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

Татарстан төзүчеләре быел торак тапшыру буенча еллык планны 8,5 процентка арттырып үткән.

2 млн 990 мең кв. метр торак тапшырылган

Күпфатирлы инвестиция торагы >> **747 мең** кв. метр

Шәхси торак төзелеше >> **2 млн 137 мең** кв. метр

Социаль ипотека >> **105,8 мең** кв. метр

Чак кына калган

Быел февраль аенда Татарстанда чак кына эшләми торган көннәр кертелмичә калган. Республика сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Абашев әйтүенчә, шул айда төбәктә коронавирус йоктыручылар саны бик нык күбәйгән булган. «Без асылда локдаунга якынлашкан идек. Сырхауханәгә бармыйча, телефон аша гына «больничный» алу мөмкинлеге булдырдык. Бу чара безгә авыр хәлдән чыгу мөмкинлеге бирде», – диде ул.

Аның әйтүенчә, хәзер чирнең җиңелрәк штаммы өстенлек итә: узган елда «дельта» булса, бүген «омикрон» һәм аның төрләре. Әлеге штамм күпкә җиңелрәк кичерелә. Әмма, табиб әйтүенчә, бу ковидны җиңүебезне аңлатмый, чөнки вирус әледән-әле үзгәреп тора.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Гайбәт – мәгълүматмы?

Без мәгълүмат заманында яшибез. Алай гына да түгел, без мәгълүмат күләме коточкыч тиз артып торган чорда гомер итәбез. Телевизордагы йөзләгән каналның һәрберсе аның саен яңалыкларга бүленә. Яңалык ирештерелмәгәндә дә телевизор дигән «такта» ниндидер башка мәгълүмат җиткерә. Интернетта, гаджетларда да шул ук хәл: кайчан ышкыма, кырыкмаса-кырык төрле хәбәр, су буе яңалыклар тасмасы – карап, үзләштереп кенә өлгер. Ул радио, газеталар. Көн саен башка ишелеп торучы мәгълүмат ташкыныннан каядыр карурманга качып, шунда куыш корып яшәгәндә генә котылып буладыр. Анда да смартфоныңны махсус өендә онытып калдырсаң…

Бүген – Бөтендөнья мәгълүмат көне (World Information Day). Чамаласак та, «Мәгълүмат ни-нәрсә соң ул?» дигән сорау куеп карыйк. Ул – кемдер яисә кемнәрдер икенче берәүләргә юллаган хәбәр. Кемдер аны җиткерә, икенче берәү кабул итеп ала. Ике кеше урамда очрашып гәпләшкәндә бер-беренә ниндидер мәгълүмат ирештерми калмый. Хәтта гайбәт тә, ул хакыйкатьтән ерак торган тәкъдирдә дә, барыбер мәгълүмат санала ала. Чөнки аның ялган икәне әле исбатланмаган. Глобаль мәгълүмат кырында да шундыйрак хәл күзәтелә. Хагы булган кебек, кемнеңдер мәнфәгатьләренә хезмәт иткән нахагы да җитәрлек. Аның ишене хәзер кыска сүз белән «фейк» дип атыйлар.

Шунысын да искәртик: мәсәлән, шул ук телевизор очрагында, хәбәр кабул итүчеләр миллионнар белән исәпләнгәнлектән, нахак сүз, фейк китергән зарар, аерым гайбәтче белән чагыштырганда, гадәттә, исәпкә бирешмәс дәрәҗәдә зур була.

Элекке заманнарда аерым кешегә тәгаенләнгән мәгълүмат күләме күпкә азрак булган, яңалыклар кемнеңдер колагына ирешкәнче озын юл үткән. Ялган да шактый ким булган. Хәбәр авылдан авылга, кешедән кешегә йөргән. Хат язып, мәгълүмат алышканны әле дә хәтерлибез. Борынгы чорларда, язу уйлап табылганчыга кадәр дә мәгълүмат җиткерү юллары булган: адресатка агач кисәгенә нидер сырлап, нәрсәнедер аңлаткан тамга-билгеләр юлланылган. Бөек Кытай стенасы сакчылары дошман якынлашканны манара башына учак ягып хәбәр итә торган булган. Башка манаралар һәм якын-тирәдәге халык төнлә учак утын, көндез төтен баганасын күреп, дошманга каршы торырга әзерләнгән…

Хәзер башка заманнар, учак ягып торасы юк. Хат язып та мәшәкатьләнмиләр. Кесәңнән телефоныңны алып, Җир шарының икенче ягындагы кешегә иртән нәрсә ашаганыңны җиткерү берни тормый. Телевизор, интернет ише массакүләм чаралар да кирәкле хәбәрне көнендә-сәгатендә генә түгел, минутында миллионнарга ирештереп тора. Искәртүебезчә, хилафлык шунда: ирештерелгән сүз, хәбәр, мәгълүмат чарасын «ашатучы» хуҗа теләгән кимәлдә булырга, ягъни дөреслеккә тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Массакүләм мәгълүмат чараларының мәкерле ягы нәкъ шунда да инде.

Менә шушы урында «Мәгълүматка хуҗа булган – дөньяга хуҗа» дигән гыйбарә килеп чыга да. Аның ралуына күп булса бер гасырдыр. Башкача әйткәндә, мәгълүмат кулланып, яхшыны да, начарны да кылып була. Үгетләү, коткы тарату, халыкның башын әйләндерү берни тормый. Гавамны хәбәрдар итү дә, буйсындырып тоту да җиңел. Барысы да иленә, андагы идарә ысулына карап. Шуңа да, мәгълүмат бүген акчадан кыйммәтрәк йөри, дип әйтү һич тә арттыру түгел. Феодализм чорында, белүебезчә, җир, биләмәләр беренче кыйммәт саналган. Капитализмга кергәч, җирне җитештерү чаралары – төрледән-төрле станоклары белән завод-фабрикалар алыштырган.

Бүгенге цифрлашкан телевидение, югары тизлектә эшләүче интернет, мобиль элемтә заманында беренче урынга мәгълүмат чыкты. Нәкъ шул сәбәпле, хәтсез тарафларда мәгълүматка бүген дәүләт монополиясе. Хәбәрләр, яңалыклар, аналитик тапшырулар халыкка нечкә иләк аша сөзелеп, дәүләт теләгәнчә итеп бирелә. Болай эшләү – алар өчен халыкны «кулда тоту»ның төп юлы. Хәбәрне сөзеп кенә калмыйча, аңа кемнедер начарга чыгарган, гаепләгәнне дә кушып җибәрсәң, пропаганда дигән нәрсә килеп чыга. Пропаганданы башкача берьяклы үгет дип атап та буладыр. Дөньяда, илдә барган вакыйгаларга, хәлләргә, хәтта тарихка да дәүләт, аның идеологлары, идарәче даирәләре теләгәнчә карау һәм шуны гавамга ирештереп тору.

Пропаганданың начарлыгы – хакыйкать, объективлык белән санлашмау. Тик гади халык аны һәр очракта да алай кабул итми. «Телевизор чаклы телевизордан кем ялган сөйләп утырсын инде», – дип уйлый ул. Гади кеше сәясәтчеләр, дәүләт башлыклары, шулай ук үзләрен дөнья кендеге санаучы үтә байларның шул рәвешле үз мәнфәгатьләрен саклавына һәм кайгыртуына да бик төшенми. Югыйсә бүгенге Төньяк Корея тоталитар режимның мәгълүмат чаралары ярдәмендә халыкның аңын бөтенләй томалап тотканлыкны аңышыр, мыегына чорнап тотар иде. Фашизм турындагы язмада искәртелгәнчә: «Сез миңа гавами мәгълүмат чараларын гына бирегез, мин теләсә кайсы халыктан дуңгыз көтүе ясыйм». Ясаганнар да. Германия нацизмы халыкларга китергән гарасат-михнәтне – 65 миллионга җиткән корбан, хәрабәгә әйләнгән шәһәр-авылларны, елга булып аккан канны кешелекнең онытырга хакы юк. Пропаганда машинасының танк, туплардан да хәтәррәк булганын барыбыз да белеп торырга тиеш.

Бәладән котылуның бердәнбер диярлек юлы – мәгълүматка монополияне булдырмау. Мәгълүмат кырында фикер төрлелеге сакланмаганда күркәм тормыш гарантияләнә алмый. Карашларның һәммәсен тыңлап, карап, укып, үзең нәтиҗә чыгарганда гына күмәк гипноздан котылып була. Күптән билгеле хакыйкать: фикер төрлелеге булган тарафларда үсеш, алгарыш тизрәк бара. Хакыйкать тә бәхәстә генә туа. Дәүләттәге кыйммәтләр, дәүләтнең кыйбласы барлык якларны, бар фикерне истә тотып сайланырга тиеш. Бөтен кеше дә бер төрле генә уйлаган җирдә беркем дә уйламый. Уйсыз яшәеш исә кешегә лаек яшәеш түгел. Фикер, мәгълүмат төрлелеге ул – гавамның активлыгы, дәүләт белән идарә итүдә катнашуы да…

Мәгълүматка ихтыяҗ – кешедәге табигый сыйфат. Һәрберебез, көн туса, аны кабул итә, үзенчә эшкәртә, үз фикерен формалаштыра, башкалар белән бүлешә. Һәм бу гадәт нәкъ менә мәгълүмат, фикер төрлелеге булганда күпкә нәтиҗәлерәк эшли, җаваплылык, социаль уяулык тудыра. Ә уяулык, үз чиратында, иминлек, тыныч яшәеш тәэмин итәргә сәләтле.

САНЛЫ АҢЛАШУ

Тәҗрибә уртак булсын. Иннополис шәһәрендә Digital Innopolis Days 2022 форумы узды. Чарада цифрлы тормыш, алгарыш һәм киләчәк турында сүз барды. Форумның пленар утырышы федераль министрлар һәм республика җитәкчелеге катнашында узды. Аны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко алып барды.

Мәгариф, фән һәм индустриянең берләшүе илнең кадрлар һәм фәнни-тикшеренү юнәлешендә мөмкинлекләрне үстерү өчен этәргеч була ала. Форумның төп темасы да шуңа багышланган иде.

Форум катнашучыларын сәламләп, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, әлеге чарада игътибарга алыначак төп юнәлешләрнең берсе – Россия төбәкләрен цифрлы трансформацияләү булуын белдерде. «Татарстан бу җәһәттән лидер буларак, үз тәҗрибәсе белән уртаклашырга әзер», – диде ул.

Компанияләрнең ихтыяҗын аңлап кына, яхшы белгечләр әзерләп була, дигән фикердә Президент. «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проекты – шуңа бер адым да инде.

Вице-премьер Дмитрий Чернышенко әйтүенчә, хәзер импортка нәтиҗәле алмаш әзерләү өчен дә цифрлы күнекмәләре булган югары квалификацияле белгечләр кирәк. Хөкүмәт бу җәһәттән эш алып бара инде. 216 проект гамәлгә куелган, аларны тормышка ашыру өчен 200 меңләп яңа белгеч кирәк.

tatarstan.ru

– Иннополис университеты базасында эшләүче үзәк безгә бу юнәлештә терәк булачак. Хәзер без бу үзәкне импортка алмаш бурычларын үтәү өчен үзгәртеп корырга тиеш, – диде Дмитрий Чернышенко.

Яхшы укыр өчен торак шартларының да яхшы булуы кирәк. Кичә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко белән берлектә, Иннополистагы өч яңа тулай торак төзелеше белән танышты.

Моңа өстәп республика җитәкчесе һәм Хөкүмәт Рәисе урынбасары биналар эксплуатациясендә кулланыла торган мәгълүмати модельләштерү технологиясе (ТИМ) эшен дә тикшерде.

– Россиядә җитештерелгән программа тәэминаты нигезендә Иннополиста эшләтеп җибәрелгән система ул. Ул бинаның барлык коммуникацияләре – җылылык, электр, интернет челтәрләре белән нәтиҗәле идарә итәргә мөмкинлек бирә, – диде Дмитрий Чернышенко. Аның сүзләренчә, әлеге системаны бөтен ил буенча гамәлгә кертергә ният бар.

Иннополистагы тулай торакларга килгәндә, алар Россия Президенты тәкъдиме белән барлыкка килгән «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысасында төзелә. Федераль бюджеттан бина төзелеше өчен 2,5 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Киләсе елдан бирегә беренче студентлар урнаша алыр дип көтелә.

– Бүген илебезнең технологик мөстәкыйльлеген тәэмин итү бурычы беренче планга чыга. Бу барлык өлкәләргә, шул исәптән төзелешкә дә кагыла, – диде Рөстәм Миңнеханов та бу җәһәттән. Аның сүзләренчә, 2022 ел азагына төзелеш-монтаж эшләре төгәлләнергә тиеш.

* * *

Ун яшьтә нинди уңышларга ирешеп була? Иннополис университеты, мәсәлән, республика өчен генә түгел, ил өчен дә шактый тырышкан. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко белем йортын 10 еллыгы белән котладылар.

Дмитрий Чернышенко югары уку йортының иң яхшы 14 хезмәткәренә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Россия Хөкүмәтенең Рәхмәт хатларын тапшырды. Рөстәм Миңнеханов исә, педагогларны һәм студентларны югары уку йортының 10 еллык юбилее белән котлап, Татарстан Хөкүмәтенең Рәхмәт хатларын, «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медален тапшырды.

– Университет командасы көн саен «Цифрлы трансформация» илкүләм проектының бурычларын үтәүгә үз өлешен кертә, – диде Россия вице-премьеры.

Рөстәм Миңнеханов исә Дмитрий Чернышенкога уртак хезмәттәшлек өчен рәхмәт әйтте.

– Яңа геосәяси чынбарлыкта Россия һәм аның төбәкләренең цифрлы мөстәкыйльлеген тәэмин итү мәсьәләләре аеруча актуальләшә. Иннополис университетының «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль программасы кысасында гамәлгә ашырыла торган проектлары аларны нәтиҗәле хәл итәргә булышыр дип ышанам, – диде Татарстан Президенты.

ЙӨРӘК КУШКАНГА

«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсы бу өлкәдә эшләүчеләргә ярдәм итү һәм яңа алымнар булдыру максаты белән үткәрелә. Конкурста педагоглар, депутатлар, полиция хезмәткәрләре, судьялар, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре, журналистлар, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре катнашты.

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында үткән бүләкләү тантанасында катнашучыларны Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева сәламләде.

– Сез үз хокукларын һәм бурычларын аңлый торган гражданнарны тәрбияләүдә катнашасыз. Ялгышканнарга дөрес юлга басарга ярдәм итәсез һәм бу бик мөһим. Балигъ булмаганнарга игътибарыгыз өчен зур рәхмәт сезгә, – диде Ләйлә Фазлыева. – Бүген балалар белән эшләү җиңел түгел һәм моны әти-әниләр дә, педагоглар да аңлый. Җәмәгать тәрбиячесе булу – авыр хезмәт. Балигъ булмаганнар сезнең ярдәмегез белән үсә һәм алга бара. Укырга әзер булган баланы укыту җиңел, ә менә укырга теләмәгән баланы өйрәтү бик катлаулы. Бу мәсьәләдә һәрчак ярдәмчеләр кирәк.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Юлия Абдреева да җәмәгать тәрбиячесенең зур әһәмияткә ия булуын ассызыклады.

– Балалар турында кайгырту, гаилә иминлеген саклау безнең барлык социаль проблемаларыбызны хәл итүдә беренче планга чыга. Сез башкарган эш безнең республикадагы һәр кеше өчен бик мөһим. Хезмәтегез өчен бик зур рәхмәт сезгә. Чит кеше баласы өчен үз өстенә җаваплылык алырга һәм аны яңа тормыш юлына чыгарырга һәркем батырчылык итми. Гаиләләрегездә һәрвакыт иминлек булсын, иҗади көчегез, энергиягез ташып торсын һәм иң мөһиме, чит балалар булмавын исегездә тотыгыз, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

ӘТИНЕ КӨТКӘНДӘ

Яшәеш

Кечкенә Мирсәет әтисен сагына. Әтисе, хәрби операциягә киткәндә, улына нидер әйткән дә әле. Сабый ул сүзләрне сер итеп саклый. Әмма кайткач, әтисенең үзенә ни алып бирәсен төгәл белә ул. Мирсәетнең чын мотоциклы булачак! Бу хакта ул Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионовага да сөйләде.

Татарстанда ирләре, уллары өлешчә мобилизациягә эләккән ханымнар һәм әниләр белән очрашулар башланды. Татьяна Ларионова Дәүләт Советы депутаты Динар Бариев белән кичә ике гаиләнең хәлен белде.

Мирсәетнең әнисе Әлфиянең эш урынында күрештек. Ул анда кечкенә улын да ияртеп килгән иде. Мирсәет икенче елга мәктәпкә барачак. Ул бик тә әтисенең кайтуын көтә. Әлегә сабый аның кая киткәнен бик аңлап бетермәсә дә, геройга саный. Мирсәетнең дә әтисе төсле көчле буласы килә. Әнә шуңа да ул каратэ түгәрәгенә йөри башлаган. Әтисенә сүз дә биргән: тырышып укыячак, әбисен, әнисен, абыйсын тыңлаячак. Әле каратэ белән шөгыльләнеп, кара билбау да алачак!

– Иремне 31 октябрь көнне озатып калдык. Мин гел бер теләктә – ирем исән-сау әйләнеп кайтсын. Догалар укыйм. Әни дә гел Аллаһы Тәгаләдән сорый. Ана догасының кабул буласына бик ышанам, – ди Әлфия Мөшәрәпова. – Соңгы шалтыратуы да әнисенә булган. «Без – окопта, әлегә ашарга бар», – дигән дә, шуның белән элемтә өзелгән. Җанымның телгәләнүен белсәгез иде. Әле мин, улларыма карап, яшәү көче алам. Беренче никахтан туган улыма тиздән 18 яшь тула. Әни буларак, шул баланы каядыр чыгарып җибәрүне күз алдына да китермим. Мин каенанамны ныграк кызганам. Ул бик өзгәләнә. Солдат хатыннарына, балаларына гына түгел, аларның әниләренә дә игътибар булсын иде.

Балалар дигәннән, Әлфия улына тиешле 20 мең сум акчаны алган инде. Татьяна Ларионова да Мирсәет янына буш кул белән килмәгән иде. Әлфияне Әниләр көне белән котлап, чәчәк, торт бирсә, Мирсәеткә әтисенә хат язар, рәсем ясар өчен кирәк-яраклар тутырылган букча тапшырдылар. Малайның күңеле күтәрелеп китте. Ул хәтта депутат ханымның кочагына барып сарылды. Татьяна Ларионова исә сабыйны үзе дә кысып-кысып кочаклады. Әлфияне борчыган сорауларны да тыңлады ул. Якын арада аларга җавап бирәсен әйтте.

Казанның Завойский урамында яшәүче Турцевлар кунакларны бигрәк тә шатланып каршы алды. 10 яшьлек Дарья белән 7 яшьлек Станислав иң элек Татьяна Ларионовага фатир буйлап экскурсия ясадылар. Сабыйларның сөйләшер сүзләре күп җыелган. 10 минут уздымы икән, инде Дәүләт Советы депутаты ике баланың бар шөгылен, нинди билгеләргә укуларын, сыйныфларында ничә бала икәнен – барысын да белә иде. Соңрак алар бөтенесе бергә чәй табыны янында сөйләштеләр. Әтиләре Максим армия сафларында булган, Чечняда хезмәт иткән. Махсус хәрби операциягә чакыру башлануга, повестка килсә, китәм, дигән.

– Мин иремне бер күрүдә яраттым. Никахыбызга – 13 ел. Бер-беребезне аңлап яшәдек. Фатир алгач та, тизрәк түләп бетерик дип, Себергә китеп эшләп йөрде. Аннан кайтып күп тә үтмәде, тагын чыгып китте. Без аның белән гел элемтәдә тордык. Тик менә 10 көннән артык инде, шалтыратмый. Нәрсә уйларга белмим, ярый әле сабыйларым бар дип, алар белән юанам, – ди Ирина Турцева.

Балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче ханым, сабыйларсыз тора да алмый. Ул үз төркемендәге балаларны бик яратуын әйтә. Эшеннән зарланмый. Бар да бар, тик күңел тынычлыгы юк аның.

– Иремнең документлары тәртиптә түгел иде. Артыннан йөрергә туры килде. Ә бит минем кебек ханымнар күп әле. Безнең махсус төркемебез бар. Шунда сөйләшәбез. Әлегә кадәр иремнең хезмәт хакы да күчмәде, – ди ул.

Ирина бу проблемаларны Татьяна Ларионовага да җиткерде.

– Ирләре өлешчә мобилизациягә эләккән ханымнарга игътибар булырга тиеш. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бу гаиләләргә карата җылы мөнәсәбәттә булуыбызны үтенде. Бу гаиләләр безнең яратуны, кайгыртуны тойсыннар. Гаиләдә балалар да бар. Алар быелгы Яңа ел бәйрәмен дә әтиләрен юклыкны сизмичә үткәрергә тиеш. Безгә бу гаиләләрне тыңларга, аларның үтенечләрен бик кыска вакыт эчендә үтәргә кирәк, – ди Татьяна Ларионова. – Күптән түгел генә әтиләре кайтуны көтүче балалар белән очраштым. Алар үзләренә булган мөнәсәбәттән балкыйлар. Күзләреннән рәхмәт сүзләрен укып була иде. Алар әтиләре белән горурлана. Без шул сабыйларны тагын да сөендерә алсак иде.

Динар Бариев сүзләренчә, очрашулар дәвам итәчәк.

– Әниләр көне уңаеннан, без ирләре мобилизациягә эләккән ханымнар өчен психологлар белән очрашулар уздырдык. Кичә ике гаиләдә булдык. Тагын 20 гаиләгә барачакбыз. Ханымнарның нинди борчулары барын да сорашабыз. Аларын хәл итәргә тырышабыз, – ди ул.

Дарья белән Станислав та депутатлар белән очрашуны бик озак оныта алмаслар әле. Татьяна Ларионова да ул балаларны исендә тотарга вәгъдә бирде. Бергәләп гаилә фотоларын карадылар. Баксаң, Станислав соравы буенча, әтисенең сурәте зурайтып бастырылган икән. Әлегә балалар шуңа карап сөенә. Әмма күңелләре сизә: тиздән аларның газиз кешеләре ишек шакыячак!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Әни – изге кеше

Әниләр көне уңаеннан республикадагы барлык әниләрне Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева котлады.

«Әни – һәркемнең тормышында иң изге кеше, – диелә котлауда. – Балачакның эчкерсез мәхәббәт белән сугарылган иң җылы, иң тәэсирле хатирәләре әниләргә бәйле, Әниебезнең изге, зирәк киңәшләре безгә көч һәм илһам бирә. Ана чын күңелдән баласының сынатмаячагына ышана.

Гаҗәеп наз һәм рухи ныклыкны берләштергән хатын-кыз-ана образына шагыйрьләр, рәссамнар дан җырлый. Илебездә хатын-кыз-ана гаилә традицияләрен саклаучы, тотрыклылык һәм ышанычлылык символы булып тора. «Герой ана» исемен горур йөртүче күпбалалы аналарга гаилә кыйммәтләрен, милли кыйммәтләрне, ана культурасын саклаулары өчен аерым рәхмәт!

Сезгә, кадерле аналар, нык сәламәтлек, гаилә бәхете һәм иминлек телим! Якыннарыгызның мәхәббәтенә төренеп, балаларыгызның уңышларына сөенеп яшәгез! Һәр көн саен үзегезгә: «Әнием, мин сине яратам!» – дигән сүзләр ишетергә язсын!»

Уен алдыннан уйнап алалар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Tubetey Power» дип аталган командада йөзү буенча халыкара класслы спорт остасы Дарья Муллакаева белән бергә татар блогеры Ринат Галиәхмәтов та чыгыш ясаган. Ринатның бу уеннардан алган хис-кичерешләре ташып тора, дип әйтү генә аз.

– Искиткеч булды! Безгә шулкадәр ошады. Бу кадәр игътибар үзәгендә булган юк иде әле. Андагы камералар, «туры эфир»… Кешеләр дә шундый позитив! Бөтенләй башка дөньяга килеп эләккән төсле булды, – ди блогер. – Дарья да: «Болай булыр дип көтмәгән идем», – дип шаккатты. Бу – чынлап та, киләчәк уеннары. Әле бит ярышларның иң зуры 2024 елда гына булачак. Бу әзерлек кысасында уеннар санала. Әзерлек уеннары дигәне дә шулкадәр югары дәрәҗәдә оештырылган икән, безне алда тагын да кәттәрәк нәрсәләр көтә дигән сүз. Мондый формат – яңалык.

Беренче карашка, картинг – бик җиңел ярыш кебек. Бәләкәй машинага (карт дип атала. – **Авт.**) утырасың, зур тизлек белән әйләнеш ясыйсың да, бетте. Тик чынлыкта карт рулен тоту да җитди әзерлек таләп итә икән. Ярышта катнашкан блогер Рәзилә Матурова да шуңа инанган әнә.

– Әйләнештән соң бармакларым бөгелмәде, тамырларым шешеп чыкты. Ләкин бик кызык булды! – ди ул.

Кичен исә чын профессионаллар ярышты. Аларга картингта 20 әйләнеш ясарга, аннан виртуаль стимуляторда 10 әйләнеш оештырырга кирәк иде. Нәтиҗәдә спортчылар Борис Гарифуллин һәм Михаил Стаценко «Фиджитал уеннар»ның чемпионнары булып танылды.

– Җиңүче җиңүен ничек билгеләп үтүе турында уйламый. Ул киләсе стартта тагын ничек җиңәчәге хакында уйлый, – диделәр егетләр тыйнак кына.

Башка төрле көрәш

26 ноябрьдә исә фиджитал-көрәш буенча турнир узачак. Ярышта 73 килограммга кадәр авырлык категориясендә катнашучылар белән командалар чыгыш ясаячак. Спортчылар башта Mortal Kombat 11 уенында көч сынашачак, ә аннары ММА кагыйдәләре буенча барган көрәштә физик яктан осталыкларын күрсәтәчәк. Җиңүчеләр 700 мең сум акча белән бүләкләнәчәк.

УЕННАР ТУРЫНДА ФАКТЛАР

✓ Ярышларда Россия, Казахстан, Беларусь, Иран командалары көч сынаша.

✓ Акчалата бүләк фонды – 5,5 млн сум. Аны өч дисциплина җиңүчеләре арасында бүләләр.

✓ Уеннарга танылган шәхесләр дә кунак буларак килә. Әйтик, UFC (катнаш көрәш буенча иң көчле лига) спортчысы Петр Ян; стримерлар Дмитрий Ликс, Илья Яцкевич, автоузышчылар Никита Мазепин, Алексей Басов, Сергей Сироткин, Виталий Петров, Олимпия чемпионы Никита Нагорный.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

2023 елга, 2024 ьәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

1. 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 343 933 710,3 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 371 081 210,8 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 27 147 500,5 мең сум итеп.

2. 2024 елга һәм 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2024 елга 367 407 890,2 мең сум һәм 2025 елга 366 968 259,3 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2024 елга 394 637 646,2 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 9 900 000,0 мең сум итеп, һәм 2025 елга 394 354 206,1 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 21 100 000,0 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 2024 елга 27 229 756,0 мең сум һәм 2025 елга 27 385 946,8 мең сум итеп.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2024 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 99 387 639,1 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 9 527 692,3 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 9 527 692,3 мең япон иенасы күләмендә расларга.

2. 2025 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 97 890 620,9 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы күләмендә расларга.

3. 2026 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 89 042 900,0 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2023 елга 6 103 099,2 мең сум, 2024 елга 5 811 892,3 мең сум һәм 2025 елга 5 534 768,1 мең сум күләмендә расларга.

5. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. 2023 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бердәм бюджет счетында калган акчаларны тулыландыру өчен бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукын бирергә.

3 статья

Татарстан Республикасы бюджетында 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60^{1} статьясындагы 2 пункты нигезендә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәрен әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

6 статья

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2022 ел нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2023 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табыштан кимендә 30 процент күләмендә акчалата түләү өчен табыш бирергә тиеш.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2022 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2023 елның 1 июленә кадәр әлеге табыштан 30 процент күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

7 статья

1. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты тарафыннан гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2023 елга 10 091 199,3 мең сум, 2024 елга 7 545 325,2 мең сум һәм 2025 елга 7 805 958,9 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2023 елда үзгәрешләр кертү өчен әлеге статьяда расланган, бюджетлар чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендәге «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча каралган бюджет ассигнованиеләре составындагы резервланган акчаларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча түбәндәгечә бүлү нигез булып тора дип билгеләргә:

1) оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә 2023 елга 1 832 406,4 мең сум, 2024 елга 1 882 442,0 мең сум, 2025 елга 1 932 680,0 мең сум күләмендә;

2) бюджет өлкәсе учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга юнәлдерелә торган чараларны гамәлгә ашыруга 2023 елга 6 356 439,0 мең сум, 2024 елга 6 610 696,6 мең сум, 2025 елга 6 875 124,4 мең сум күләмендә;

3) аерым категорияләргә гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга 2023 елга 1 103 440,0 мең сум, 2024 елга 1 147 577,6 мең сум, 2025 елга 1 193 480,7 мең сум күләмендә;

4) гражданнарның ихтыяры салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын башкаруга 2023 елга 1 352 100,0 мең сум, 2024 елга 1 352 100,0 мең сум, 2025 елга 1 352 100,0 мең сум күләмендә;

5) дәүләт (муниципаль) бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренә (эшләр башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә 2023 елга 1 500 000,0 мең сум, 2024 елга 1 500 000,0 мең сум, 2025 елга 1 500 000,0 мең сум күләмендә.

8 статья

Товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүче юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга әлеге Законда каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

9 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^{10} статьясы нигезендә 2023 елда, 2024 һәм 2025 еллар план чорында җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^{10} статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен финанс хисабы елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2023 елда – 3 процентын, 2024 елда – 5 процентын, 2025 елда 5 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

10 статья

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

1) 2023 елга – 18 280 653,2 мең сум;

2) 2024 елга – 19 580 568,7 мең сум;

3) 2025 елга – 21 032 264,1 мең сум.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2023 елда 17 518 985,6 мең сум, 2024 елда 18 828 447,6 мең сум, 2025 елда 20 207 427,0 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырырга.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак кулланыла торган күрсәткечне 2023 елга – 2,264, 2024 елга – 2,264, 2025 елга 2,264 итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләрне исәпләгәндә кулланыла торган әлеге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкару буенча шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен түбәндәгечә билгеләргә:

1) шәһәр җирлекләре буенча: 2023 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 670,0 сум, 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 644,1 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 671,2 сум;

2) авыл җирлекләре буенча: 2023 елга – бер кешегә исәпләгәндә 260,6 сум, 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 265,9 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 266,9 сум.

11 статья

1. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 11 – 43 кушымталар нигезендә расларга.

2. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субсидияләр исемлеген әлеге Законга 44 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга конкурс нигезендә муниципаль берәмлекләр арасында бүленә торган субсидияләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрне һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фонды исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

12 статья

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләү өчен җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2023 елга 17 589 896,8 мең сум, 2024 елга 18 877 681,7 мең сум, 2025 елга 20 126 759,3 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2023 елга 9 384 576,2 мең сум, 2024 елга 9 510 116,5 мең сум, 2025 елга 9 639 615,3 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасында билгеләнмәгән медицина ярдәменең өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2023 елга 1 761 059,2 мең сум, 2024 елга 1 787 252,0 мең сум, 2025 елга 1 813 480,0 мең сум күләмендә;

2) «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән очракларда чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә 2023 елга 7 623 517,0 мең сум, 2024 елга 7 722 864,5 мең сум, 2025 елга 7 826 135,3 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

13 статья

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2023 елга 45 882 572,2 мең сум, 2024 елга 47 416 531,4 мең сум, 2025 елга 32 248 118,6 мең сум күләмендә расларга һәм аларны тиешенчә 2023, 2024 һәм 2025 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

14 статья

Инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган акчаларның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2023 елга – 100 000,0 мең сум;

2) 2024 елга – 100 000,0 мең сум;

3) 2025 елга – 100 000,0 мең сум.

15 статья

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2023 елда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз, моңа Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирелүгә бәйле шундый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирле үзидарә органнарына 2023 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

16 статья

1. 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җирле бюджетларны финанслашу (аларны финанс белән тәэмин итү) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган мондый бюджетара трансфертларны җирле бюджетлар акчаларын алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләтләрен тапшыру турында карарларны Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара трансфертлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

17 статья

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 45 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга:

1) федераль бюджеттан 2023 елда 61 882 504,0 мең сум, 2024 елда 64 621 782,5 мең сум, 2025 елда 42 780 040,6 мең сум күләмендә;

2) дәүләт корпорациясеннән – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фондыннан 2023 елда 51 019,3 мең сум күләмендә.

18 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

19 статья

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары буенча түләү өчен бирелгән, шушы контрактлар шартлары нигезендә 2022 елда түләнергә тиешле файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2022 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый бюджетара трансфертларны бирүгә бюджет ассигнованиеләренең, финанс белән тәэмин итү чыганагы юридик затларга субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2022 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый субсидияләрне бирүгә бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасыннан артмаган күләмдәге Татарстан Республикасы бюджетының 2023 елның 1 гыйнварына калган акчалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2023 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

20 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, суд эшчәнлеге турындагы, үтәтү эшен алып бару эшчәнлеге хакындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93^{8} статьясындагы 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычны җайга салу шартларын билгели торган, акчалата йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору яисә аларны өлешләп түләү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү хакында ризалык килешүләре төзергә хокуклы.

21 статья

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны ирекле рәвештә каплаганда түләнә торган түләүләрдән Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының табигатьне саклау чаралары планы нигезендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм бәяләүгә һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыруга, хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану һәм аларны яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга җибәрелә дип билгеләргә.

22 статья

2023 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацының (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әлмәт муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш;

4) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш.

23 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 23 ноябрь
№ 82-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

2023 елга, 2024 ьәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба шулай ук – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 70 598 941,5 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 60 186 154,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 9 384 576,2 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 70 598 941,5 мең сум итеп.

2. 2024 һәм 2025 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 75 113 089,6 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 9 510 116,5 мең сум, һәм 2025 елга 78 834 472,2 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 9 639 615,3 мең сум итеп;

2) 2024 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 75 113 089,6 мең сум һәм 2025 елга 78 834 472,2 мең сум итеп.

2 статья

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2023 елга әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

3 статья

Фонд бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2023 елга әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә;

2) 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә.

4 статья

Фонд бюджетын үтәгәндә әлеге Закон белән расланган күләмнәрдән тыш фактта алынган һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры китереп, Фонд бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

5 статья

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

6 статья

1. 2023 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 7 675 132,1 мең сум итеп билгеләргә.

2. Нормалаштырылган иминият запасы акчалары түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны медицина ярдәменә түләү өчен җитми торган акчаларны «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше нигезендә иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар ясауга;

3) квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

4) медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашуга;

5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре кимелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

7 статья

Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар нормативын мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 0,95 процент күләмендә билгеләргә.

8 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3^{1} пункты нигезендә 2023 елда Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр булып түбәндәгеләр тора дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү;

2) 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3^{2} пунктының өченче – алтынчы абзацларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертү;

3) 2023 елга бюджет ассигнованиеләрен әлеге Законда «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе, «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү» максатчан статьясы буенча каралган бюджетлар чыгымнары классификациясе чыгымнары төрләре арасында 2023 елда чыгымнарның күрсәтелгән бүлеге, бүлекчәсе һәм максатчан статьясы буенча бюджет ассигнованиеләрен файдаланганда экономияләү хисабына яңадан бүлү;

4) 2023 елда Фонд бюджетына әлеге Закон белән расланган 2023 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән тыш медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелергә тиешле акчалар керү.

9 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 23 ноябрь
№ 83-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

БЕЗДӘН ӘЛЕ ЯШЬЛЕК УЗМАГАН

Болыннарда атлар табырлаган,
Бер җыр ишетелә табуннардан:
«Дөрләп яна каен тузлары,
Бездән әле яшьлек узмады…»

Йөрәк кагып ярсу атлар килә,
Яшь егетнең җыры ишетелә:
«Җигә белсәң, ияр тузмый ул,
Картаймасаң, яшьлек узмый ул».

Болыннарны атлар табырлаган,
Бер җыр ишетелә табуннардан:
«Нык җигелгән ияр тузмый ул,
Чәч агара яшьлек узмый ул».

Гәрәй РӘХИМ

Битараф кала алмыйбыз

Украинадагы коточкыч вакыйгаларга йөрәк әрни, күңел сызлана. Авырлыкларны аз гына булса да җиңеләйтү өчен без, ветераннар, нинди булышлык күрсәтә алабыз соң?

Татарстан агросәнәгате комплексының ветераннар оешмасы президиумы утырышында да шушы мәсьәлә күтәрелде һәм өлешчә мобилизацияләнүчеләргә, күптән түгел Россия составына кергән төбәкләрдә яшәүчеләргә мөмкин кадәр ярдәм итү кирәклегенә басым ясалды. «Теләсә нинди ярдәм яклау табачак, безнең теләкне урыннарда да ишетсеннәр иде», – диде президиум рәисе Марс Алиев һәм урыннарга хат-хәбәрләр юлланды.

Ветераннар авазын иң беренче булып Биектаудан 81 яшьлек фермер Рафыйк Гыйльметдинов ишетте. Рафыйк әфәнде – ачлык-ялангачлыкны, сугышта әтисен, абыйсын югалту ачысын кичергән шәхесебез. Заманында хуҗалык җитәкчесе дә, РАПО рәисе дә булды, аның күңеле – бары тик игелектә. «Мин үзебезнең хуҗалык басуларында үстерелгән ашлык белән булышам, – диде ул. – Ашлыкны тарттырып, онлата җибәрү, азык-төлек әзерләү мөмкинлекләре дә бар. 20 тонна чамасы ашлык бирермен, дип ниятлим».

Шәхсән мин үзем дә – Бөгелмә, Әлмәт якларында авыл хуҗалыгы тармагында җитәкче вазыйфаларда эшләгән кеше, ат үрчетүгә дә күңелем ятып тора һәм ярдәм йөзеннән ат бирергә булдым, бәлки, хуҗалык эшләрендә, бәлки, итләтә кирәге чыгар.

Игелекле эшнең башлангычы өметле һәм ярдәм итәргә теләүче ветераннар, аларның балалары, оныклары һәм дә үтенечкә битараф калмаучылар 89172557571 телефоны аша элемтәгә керә ала. Бәладән без – ветераннар да читтә кала алмыйбыз, мөмкин булганча ярдәм кулын сузыйк.

Разил СӘЕТОВ

kzn.ru

ИҢ ЯКЫНЫ – АВЫЛ КЕШЕСЕ

Чирмешән районының Кармыш авылына кунакка кайткач, авылда фельдшер булып эшләүче Вера Долгова турында бик күп мактау сүзләре ишеттем.

– Вера – Аллаһы Тәгаләбез тарафыннан безнең исәнлекне сакларга, гомеребезне тагын да озынайтырга Җир шарына җибәрелгән игелекле кеше, – ди күпне күргән, күпне кичергән 96 яшьлек Өммегөлсем әби Дәүләтшина. – Ул өйгә килеп кергәч, бүлмәләр тагын да яктыргандай була. Тыныч кына, ямьле, матур тавышы белән хәлемне сораша, кан басымын, тән температурасын үлчи, йомшак куллары белән укол ясый. Табиб язган рецептлар белән район даруханәсеннән дарулар алып кайта. Аларны куллану тәртибен җиренә җиткереп, чип-чиста татарча аңлата.

Яшәүче поселогында гомер итүче 82 яшьлек Солтан Миңнегулов Вера Николаевнаны мәрхәмәтле, эш сөючән, чын медицина хезмәткәре дип бәяли.

– Миңа аны еш чакырырга туры килә. Кайвакыт, карусызлыгыннан файдаланыпмы, сәбәпсез дә борчыйм шикелле. Эш вакыты булмаганда, ял көннәрендә чакырсам да, ярдәмгә ашыга, – ди ул.

Вера Николаевна бездә 2010 елдан бирле эшли икән. Элек Яшәүче поселогында мөдир-фельдшер булып эшләгән. 2019 елда Кармыш һәм Яшәүче фельдшер-акушерлык пунктлары берләштерелгәч, Кармышка килеп урнаша. Дөрестән дә, ул һөнәрен яхшы белә, пациентларын яратып, тырышып эшли. Пациентларын дару белән генә түгел, ягымлы, матур, мәгънәле сүзләре һәм йомшак, җылы куллары белән дә дәвалый. Олылар белән олыларча, яшьләр белән яшьләрчә, балалар белән балаларча аралаша.

Вера Николаевна өч телдә чиста сөйләшә.

– Тел белмичә әби-бабайларга даруларны ничек кулланырга кирәклеген аңлатып буламыни?! Татар телен өйрәнү авыр түгел. Безнең халыкның күп сүзләре охшаш. Татарлар да, чуашлар да – төрки телләрдә сөйләшүче халык бит, – ди ул. – Үз эшемне булдыра алганча җиренә җиткереп башкарырга тырышам. Минем карамакта дистәләгән йөрәк, шикәр чире, югары кан басымы, яман шеш белән авыручылар бар. Хәлләре начарлана башласа, ярдәм сорап, миңа шалтыраталар. Көнме, төнме, буранмы, яңгырмы – машинама утырып, авыру янына ашыгам. Кайчак ирем белән улым да алып бара.

Вера Николаевна Кармыш авылыннан – 8 чакрым, ә Яшәүче поселогыннан 12 чакрым ераклыктагы Юашка авылында яши. Тормыш иптәше Николай белән 3 бала үстерәләр. Олы уллары Николай – инженер-нефтьче, кызлары Мария – укытучы, ә кече уллары – 8 сыйныф укучысы.

– Нәселебездә табиблар булмады. Бала чакта апам Ирина белән курчак уйнаганда, без табиблар була идек. Апам да, мин дә шул һөнәрне сайладык, – ди ул. – Эшләү дәверендә күп кенә бүләкләр алдым. Әмма аларның иң якыны, канат куя торганы – авыл кешеләре. Аларның хөрмәте мине армый эшләтә дә инде.

Нариман КӘРИМОВ

ЯЗМЫШЫМ СИН…

Шулай дими, нәрсә дисен? Ул бит үзенең җыр җыентыкларының да берсен шулай дип атаган. Аның «Сине сөйдем, гүзәлем» дигән тәүге җыры Фәтхерахман Әхмәдиев сүзләренә 1953 елда языла. Ул вакытта аңа нибары унҗиде яшь була. Һәркемнең күңелендә яшьлекнең иң матур мизгеле чәчәк аткан вакыты тасвирлана ул җырда.

Сүзем – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре – абруйлы композитор, балалар күңелен яулаган оста педагог-баянчы Тәлгать Вәлиев турында.

Гаиләдә җиденче бала булып Тәлгать тугач, әтисе Абдулла абзый, балаларга уйнарга дип, гармун алып кайта. Тәлгатькә ул вакытта ундүрт яшь була, энесе белән чиратлашып уйнарга өйрәнәләр. Икесе дә оста гармунчы булып китсәләр дә, музыка дөньясы Тәлгатьне ныграк әсир итә. Бераздан кечкенә гармун зурракка, баянга алышына. Армия сафларында хезмәт иткәндә дә, буш вакытларында яшь солдатның кулында баян була.

Өч еллык хәрби хезмәтен тутырып кайткач, 1958 елда егерме ике яшьлек Тәлгать Вәлиев Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат үзәгенә эшкә урнаша, һәм гомерлеккә балалар дәрьясына чумып, алтмыш ике ел иҗади гомерен шул өлкәдә сарыф итә. Тәлгать абый анда – баянчы да, балаларның яраткан мөгаллиме дә, җырлар һәм инструменталь әсәрләр авторы да. Ул балалар өчен шаян, кызыклы эчтәлекле, җиңел кабул ителә торган сүзләр эзли, табылмаса – үзе иҗат итеп, көйгә сала. Аның иҗатташ авторлары да – танылган профессиональ шагыйрьләр: Мәхмүт Хөсәен, Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева, Резеда Вәлиева, Шәүкәт Галиев, Җәүдәт Дәрзаман, Роберт Миңнуллин, Ленар Шәех, Роза Хафизова, Дания Гайнетдинова һ.б. Бәхетемә, минем дә Тәлгать абый көенә балалар өчен җыр тексты язган тәҗрибәм булды.

Иреннәреннән ана сөте кибүгә җитәкләп алып килгән балалардан да баш тартмады олы йөрәкле, киң күңелле Тәлгать абый. Аларны ул җырлатты, елаганын көлдереп юатты, белмәгәненә төрле мәзәкләр сөйләп аңлатты, ачыкканын ашатты, арыганын йоклатты, дигәндәй, ул аларны яратып үстерде. Самими күңеле аша сиземләү белән баланың эчке дөньясын ачты, халәтен ачыклады, мөмкинлеген чамалап, талантын канатландырды, төрле бәйгеләрдә катнаштырды: «Казан сандугачы», «Без – Тукай оныклары», «Җырлыйк әле», «Кучтәнәч» кебек проектлар аша телевидениегә алып керде, шәһәр мәйданнарына алып чыкты. Ул аларга үзенең җырлары аша тормыш, юл кагыйдәләрен өйрәтте, тирә-як мохиткә игътибарлы, өлкәннәргә ихтирамлы, кечеләргә ярдәмле булу тәртибен сеңдерде. Илебезгә, туган ягыбызга карата патриотик хисләр уятып, горурлык тойгысы тәрбияләде, бер-берсе арасында дуслык-татулык ныгытты. Кыскасы, әкияти балалар дөньясының язып та, әйтеп тә бетерә алмаслык җыр-моң алиһәсе булды ул аларга.

Параллель рәвештә Тәлгать абый – шәһәребез предприятиеләренең үзешчән коллективларына да ярдәм кулын сузган кеше. «Ак калфак» дигән популяр ансамбльнең концертмейстеры, Юллар төзү оешмасының «Дорожник» клубында – баянчы-аккомпаниатор, Үзәк универсаль кибет (ГУМ) хезмәтчәннәреннән оештырылган төркемдә ансамбль җитәкчесе булып эшләде. Ул аларны балкып торган иҗади коллективлар дәрәҗәсенә күтәрде. Иҗади коллективлар белән чит илләргә дә чыкты. «Ак калфак» ансамбле белән алар Төркиягә өч мәртәбә бардылар.

Чит илләргә чыгу дигәннән, Тәлгать абый – бик актив сәяхәтче дә бит әле. «Туган якның кадерен белер өчен, чит җирләргә чыгып гыйбрәт ал», – дип җырлана бит җырда да. Ул да – үз гомерендә утыз дәүләтнең мохитен, яшәү рәвешен, табигатен, тарихын һәм үсешен, төрле шәһәрләрен, халкын күргән кеше. Румыниядән башлап, Германия, Италия, Испания, Израиль, Филиппин, Сингапур, Мисыр, Монако, Куба, Япония, Лима… – болар барысы да диңгезләр буйлап гизгән сәяхәттә үтелгән. Ул Миклухо-Маклай ачкан җирләрдә дә, бәрәңгенең туган ягы – Перу иленең тау башында да, Везувий вулканы янында – Помпейда да була. Сәяхәттә йөргәндә кызыклы очрашуларга да юлыга. Мәсәлән, Токио шәһәренең үзәк урамыннан барган чакта, каршысына килгән әфәнде аны саф татарча: «Каян беләм мин сине?!» – дип гаҗәпләнеп кочып ала. Ул «Труд» газетасының Мәскәүдә эшләүче корреспонденты – интервью алыр өчен Россия кораблена төшеп баручы Габдрахман Габдрахманов булып чыга. Шулай итеп: «Татар татарны кайда да табар», – дигән гыйбарәне бу ике милләттәш Япониянең үзәгендә исбатлый.

Һәр барган чагында җиде-сигез илнең матурлыгына хозурланып кайта да Тәлгать ага, үз Казанына булган гыйшкын аңлату өчен, яңа хисләр белән сугарылган илаһи сүзләр табып, берсеннән-берсе дәртле, моңлы җырлар иҗат итә. Композитор Тәлгать Вәлиевнең 100дән артык җыры арасында гүзәл башкаласы Казанга багышланганы да 20гә җитә. Аның җырларын яратып башкаручылар – Зифа Басыйрова, Миңгол Галиев, Әлфия Авзалова, Вафирә Гыйззәтуллина, Зиннур Нурмөхәммәтов, Винера Ганиева, Асаф Вәлиев, Римма Ибраһимова кебек профессиональ җырчылар. Тәлгать абыйда тәрбияләнеп, аның фатихасын алып чыккан хәзерге буын артистлары да бар. Аның фидакарь хезмәте абруйлы исемнәр, мактау грамоталары белән беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, Казан шәһәре башлыгы Илсур Метшин исеменнән дә югары бәяләнде.

Тәлгать абый белән безнең дуслык та бик күптәннән килә. Ул һаман да – үткен зиһенле, юморга бай җор телле, әдәпле, зыялы кеше һәм бик нечкә күңелле шәхес.

Диләрә СӘРВӘРТДИНОВА.
Казан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз һава судноларын куллану турында

Җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү, Татарстан Республикасы территориясендә иҗтимагый иминлекне, сәнәгать объектларының һәм транспорт инфраструктурасының куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында башкарыла торган чаралар турында» Указының 5 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Аларга йөкләнгән функцияләр кысаларында дәүләт хакимияте органнары һәм алар карамагындагы оешмалар, җирле үзидарә органнары тарафыннан, дәүләт хакимияте органнары һәм алар карамагындагы оешмалар, җирле үзидарә органнары белән килешү нигезендә башка оешмалар һәм физик затлар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган пилотсыз һава судноларыннан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз һава судноларын куллануны тыярга.

2. Әлеге Указ нигезендә күздә тотылган чара Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында башкарыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указының 5 пункты нигезендә кертелгән режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) бетерелгәнгә кадәр кертелә.

3. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-813

2022 елда Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В.Марковников исемендәге халыкара премияне бирү турында

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В.Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты тәкъдимен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. 2022 елда Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В.Марковников исемендәге халыкара премияне һәм «Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В.Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты» исемен Чарушин Валерий Николаевичка – Россия Фәннәр академиясе академигы, Россия Фәннәр академиясенең Урал бүлекчәсе И.Я.Постовский исемендәге Органик синтез институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе баш фәнни хезмәткәренә бирергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-814

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Саба муниципаль районының Кызыл Мишә авылыннан җиде бала анасы **Хәбибуллина** Ризәлә Ризван кызы **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Әгерҗе муниципаль районы буенча Әгерҗе шәһәреннән биш бала анасы **Козачук** Елена Николаевна, Азнакай муниципаль районы буенча Сәпәй авылыннан биш бала анасы **Шәрипова** Инга Степановна, Балтач муниципаль районы буенча Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан биш бала анасы **Сабирҗанова** Лилия Хәкимулла кызы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Авиатөзелеш районыннан җиде бала (аларның бишесе өч яшькә җиткән) анасы **Арслан** Лариса Викторовна, Яңа Савин районыннан биш бала анасы **Шакирова** Ирина Вячеславовна, Әлмәт муниципаль районы буенча Әлмәт шәһәреннән җиде бала анасы **Волкова** Наталья Олеговна, Балтач муниципаль районы буенча Куныр авылыннан биш бала анасы **Шакирҗанова** Гөлназ Рәшид кызы, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча алты бала анасы **Селезнева** Евгения Анатольевна, биш бала анасы **Чиганова** Гөлнара Илдус кызы, Түбән Кама муниципаль районы буенча Ташлык авылыннан биш бала анасы **Ибраһимова** Вәсилә Ринат кызы, Чаллы шәһәреннән биш бала анасы **Шәехова** Ландыш Заһит кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директорының дәүләт органнары белән хезмәттәшлек буенча урынбасары **Вандюков** Дмитрий Владимирович, «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы проректоры урынбасары – академик сәясәт һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру идарәсе башлыгы урынбасары **Камалетдинова** Татьяна Сергеевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе коллективы, «Материаль тәэмин итү станциясе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы

НУРИЕВ
Данил Альберт улының

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, әти-әнисе, хатыны, туганнары һәм якыннарының кайгысын уртаклаша. Сезнең белән бергә якын кешебезне югалту ачысын уртаклашабыз. Шушы авыр кайгыны күтәрергә сезгә күркәм сабырлык телибез. Якты истәлеге безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.

БӨГЕЛГӘН ТАЛ

ЦАРЕВО БИСТӘСЕНДӘ ӘТИ-ӘНИЛӘРНЕҢ ПРОБЛЕМАЛАРЫ КАР ӨЕМЕН ХӘТЕРЛӘТӘ

Борчыган мәсьәлә

Бакчада суык, урамда сабыйлар таеп егыла. Питрәч районындагы Царево бистәсендә урнашкан «Ивушка» балалар бакчасы әти-әниләре безгә әнә шулай дип хат язган. Аларны түгәрәкләрнең кыйммәт булуы, шулай ук башка проблемалар да борчый. Әти-әниләрнең моң-зарлары кайчан хәл ителер?

Сабыйлар кызганыч

«Июль аенда бакча мөдире эштән китте, аның урынына методист булып эшләгән Гөлгенә Илсур кызын куйдылар. Әмма ул үз вазыйфасын җиренә җиткереп башкармый. Безнең өчен балаларыбызның иминлеге, сәламәтлеге мөһим, – дип башлана әлеге хат. – Гап-гади нәрсәдән башлыйк әле. Бакчаның подвалына җыелган суны балалар керә торган ишек төбенә агызалар, шуның аркасында анда боз катты. Балалар таеп егыла. Берсе, аягын имгәтеп, гипс белән йөри хәзер. Ул суны куаклар төбенә, чирәмгә агызсалар да була бит. Күпме әйттек мөдиргә, әмма ишетмәделәр. Безнең төркемнең чишенү бүлмәсендә ике атнадан артык җылылык юк. Урамнан кергәч, балалар калтырап утыра. Кыш көне шундый хәл буламыни? Мөдир гел сәбәп таба: йә гариза калдырдым, йә бүген белгеч килә, ди. Ә торбалар һаман салкын. Борчыган сорауларга җавап таба алмыйбыз. Район мәгариф бүлегенә дә, министрлыкка да мөрәҗәгать итеп карадык, нәтиҗәсе булмагач, аптырап, сезгә язарга булдык. Зарланалар дип уйламагыз, балаларыбыз бик кадерле».

Әти-әниләрнең бакчада иминлек мәсьәләсе буенча да зарлары бар. Әйтик, сакчының ишектән теләсә кемне кертүенә, мөдирнең әти-әниләргә аерым ачкычлар вәгъдә итеп тә, сүзен үтәмәвенә, кайбер әти-әниләргә һаман да керү өчен пропуск ясатмавына да дәгъвалары бар. Югыйсә фотоларын майда ук биргәннәр икән. Балалар йөри торган түгәрәк бәяләренең бик кыйммәт булуына да риза түгел алар. Шахмат өчен айга 2400 сум (сигез дәрес өчен) түләргә туры килә икән. Футбол, нәфис гимнастика, менталь арифметика өчен дә шуның кадәр түлисе. «Безгә проблемаларны хәл итәрдәй мөдир кирәк», – дип үтенә алар.

Хатны алгач, иң элек әти-әниләр белән элемтәгә кердек. Әлбәттә, берсенең дә исемнәрен күрсәтәсе килми. Алар да хатта язылганнарны кабатлады.

– Казан бакчаларындагы түгәрәк бәяләре – 600–1000 сум тирәсе. Бездә исә берсенә 2000–2400 сум түләргә кирәк. Әгәр икесенә генә йөртәм дисәң дә, айлык түләү 8000–9000 сум чыга, – диде кызын бакчага йөртүче әниләрнең берсе. – Бакчага кем теләсә, шул керә ала. Каравылчы ишекне теләсә кемгә ача. Һәр төркемгә электрон ачкыч булса, балаларны тыныч күңел белән калдырыр идек. Мөдир үз эшен җиренә җиткереп башкарса, безгә артыгы кирәкми.

Мөдир сүзе

Мөдир вазыйфаларын башкаручы Гөлгенә Мостафина бакчаның өлкән тәрбиячесе икән. Хәзерге вакытта «Ивушка» бакчасына 252 бала йөри.

– Мине берәү дә рәсми рәвештә мөдир итеп куймады, августта гап-гади мәсьәләләрне генә хәл итәргә дип билгеләделәр. Монда өч ел өлкән тәрбияче булып эшлим. Мөдир булырга теләмим, бик җаваплы вазыйфа чөнки. Бигрәк тә замана әти-әниләре белән эшләргә авыр. Ашау да, йокы да юк дигәндәй. Көн саен әти-әниләрдән шикаять килә. Башка эш юк, әйтерсең, шуларга җавап кына язасы. Бакчада эш күп. Быел мәктәпкәчә әзерлек төркемнәренә 35әр бала алдык, – диде Гөлгенә Мостафина.

Балаларның таеп егылуын ул болай дип аңлатты: «Безнең бакча төзелгән урында җир асты сулары ага. Әле хәзер подвалга су элеккеге кебек күп җыелмый. Насос куйдылар, шуның белән суыртабыз. 14 ноябрьдә төнлә торба тишелеп, су аккан. Подрядчы оешма белгечләрен чакыртып, җитешсезлек бетерелде. Каткан бозны чистартып, ком сиптек. Тик аны ахырга кадәр лом белән дә ватып бетерә алмадык. Андый көтелмәгән хәлләр килеп чыккалый, бернәрсә эшләп тә булмый».

Җылылык проблемалары турында әти-әниләр мөдиргә 15 ноябрьдә җиткергән. Мөдир башта үзе хәл итеп караган, аннан җаваплы оешмага – «Мисал» инженерлык үзәгенә хәбәр иткән. Белгечләр өч көн эчендә килергә вәгъдә биргән. Ниһаять, 21 ноябрьдә торбалар җылынган.

– Бакчаны «Тайпан» хосусый сак оешмасы хезмәткәрләре саклый. Алар минем хезмәткәрләр түгел, шуңа боерык бирә алмыйм. Каравылчы теләсә кемне кертми, башта кем килгәнне белешә. Фотоларын алып килгән кешеләргә пропуск ясадык, кем озакка сузды – аларныкы юк. Һәр кешегә аерым ачкычлар бирергә рөхсәт итмиләр. Бездә хезмәткәрләрнең ачкычлары бар. Тик аны әти-әниләргә тапшырсам, нәрсә булачагын беләсезме? Ул электрон ачкыч беренче каттагы барлык ишекләрне ачачак. Бу очракта иминлек турында нинди сүз булырга мөмкин? Ачкычны югалтсалар, тапкан кеше, шуның күчермәсен ясатып, бакчага үтә ала. Яңаны ясаганда, һәркемнеке аерым булачак. Моның өчен һәр ишеккә код куярга кирәк. Монысы акча мәсьәләсенә барып тоташа, – дип җавап бирде Гөлгенә Мостафина иминлек мәсьәләсенә кагылышлы сораугa.

Түгәрәкләргә килгәндә исә, мөдир әйтүенчә, бәясен ул билгеләмәгән. Анысы өчен мәгариф бүлеге, башкарма комитет җаваплы. «Мин берничек тә үзгәртә алмыйм. Дөрес, хат язып, хореография, инглиз теле түгәрәкләрен 2 мең сумга калдырттым. Тик инглиз теле түгәрәгe булмады, белгече китте. Бәяләр чыннан да югары», – дип килеште ул.

«Ивушка» бакчасы проблемаларына ачыклык кертү өчен, Питрәч районы мәгариф бүлеге башлыгы Марина Харитоновага мөрәҗәгать иттек. Ул мөдир сүзләреннән артыгын әйтә алмады. «Мөдир табу җиңел түгел. Ике кандидатура гына бар иде», – диде ул. Марина Харитонова белдергәнчә, 3 нче категориядәге куркынычсызлык объекты буларак, «Ивушка» балалар бакчасында антитеррор таләпләре үтәлгән: балалар бакчасы территориясе койма белән әйләндереп алынган. Бакчаны «Тайпан» хосусый сак предприятиесе хезмәткәрләре саклый. Аларның эш графигы көн саен иртәнге сәгать 7дән кичке 7гә кадәр. Ә төнлә бинаны каравылчылар саклый. Бакча капкасында видеодомофоннар, магнитлы йозаклар, доводчиклар урнаштырылган. Электрон ачкычлар бары тик хезмәткәрләр өчен генә бирелгән. Әти-әниләр өчен исә электрон ачкычлар ясату каралмаган. Кәгазь пропускы булмаган әти-әниләргә, аларны алу өчен, балалар бакчасы мөдире вазыйфаларын башкаручы Гөлгенә Мостафинага мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Районның мәгариф бүлеге башлыгы сүзләренә караганда, өстәмә белем бирү хезмәтләре өчен түләүне билгеләү тәртибе Россия Мәгърифәт министрлыгының 2010 елның 20 декабрендәге 1898 номерлы боерыгы белән расланган. Түләүле белем бирү хезмәтләренә исәпне өйрәнгәннән соң, «Ивушка» балалар бакчасында хокук бозулар ачыкланмаган.

Әти-әниләрнең хатын Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына да юллаган идек. Җавап Питрәч мәгариф бүлегенеке кебек үк, шуңа күрә кабатлап торуның мәгънәсен күрмибез. Әти-әниләрнең үтенечен район җитәкчелегенә дә җиткердек. Питрәч башлыгы Илһам Кашапов бу мәсьәләнең игътибарсыз калмаячагын әйтте.

Бүген бакча, мәктәпләрдә эшләүче укытучы, тәрбиячеләргә җиңел булмавын аңлыйбыз. Балалар тәрбияләү генә түгел, һәрберсенең әти-әнисенә җавап та табарга кирәк. Ә сораулар аз түгел. Балаларның тәрбиясе дә, сәламәтлек һәм иминлеге дә шул җавапларга бәйле. Җаваплар исә тәрбияче һәм әти-әниләр уртак фикер килә алса гына табылачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Әйләнә-тирә

Китми бездән кошлар да...

Соңгы елларда Татарстанда кышларга калучы кошлар саны арта. Узган ел җылы якларга китми калган кошларның саны 2 мең 500гә җиткән. Быел да шул чама. КФУ профессоры, орнитолог Илгизәр Рәхимов аларның калуын климат үзгәрүгә бәйле дип саный.

– Климат җылыну сәбәпле, кайбер күчмә кошлар кышны бездә чыга. Күзәтүләрдән чыгып әйтә алам: аларның саны елдан-ел артып тора. Элек үрдәкләрнең калганы юк иде. Хәзер алар да китү турында уйламый, – ди Илгизәр Рәхимов. – Башта кряква дигән кыргый үрдәк кенә кала иде. Хәзер инде чумгалак дигәне дә бездә кышлый башлады. Кышлар салкын булмагач, сулыкларны боз капламый. Ашатып торучылар бар. Димәк, кошларга кышлау өчен шартлар җитә.

Кошлар туңамы? Илгизәр Рәхимов аңлатканча, аларның тән температурасы 42 градусны тәшкил итә. Әгәр азык җитәрлек булмаса, бездә кышлау авыр булыр иде. Чәүкә, саескан, кара каргаларга ризык табу кыен түгел. Алар да китми башлады хәзер.

– Кошлар өчен чүплекләрдә дә азык җитәрлек. Паркларда да җим бар. Әле менә шушы көннәрдә тәрәзә аша кошларны күзәтәм. Республикага ике атна элек кенә салкыннар килде. Суыткач, карабүрекләр килергә тиеш, дип көтә башладым. Озак көттермәделәр, килделәр. Сызылдыклар да кайтты. Ә менә миләш чыпчыклары кышка китмәде. Шул өч төрле кош, мәш килеп, миләш ашыйлар. Көтүләре белән агачка куналар да җимешләрне коеп бетерәләр. Әмма куркырга кирәкми, аларга кышын безнең паркларда азык җитәрлек, – ди орнитолог.

Кабан күлендәге үрдәкләрне күреп сокланмаган кеше юктыр, мөгаен. Алар туңмасын өчен, күлдә махсус шартлар тудырылган. Илгизәр Рәхимов: «Моннан 30 ел элек, үрдәкләр кышка калачак дисәләр, ышанмас идем», – ди.

– Быел кыш ничек булыр, әлегә белмибез. Әгәр салкыннар башланса, суны боз капласа, үрдәкләр җылы якка китәчәк. Һава торышына да ышаныч юк, бер көнне суыта, ике көннән инде боз эри. Мин үрдәкләрне китәрләр дип уйламыйм, – ди ул.– Кошлар әкренләп кешеләргә ияләнә башлады. Алар инде курыкмый. Хәтта кеше кулыннан ашаучы кошлар да бар. Ә башкалары өчен чүплектә калдыклар җитәрлек. Дөрес, кышларга калучы кошларга зыян салучылар да бар. Аларны ябалаклар аулый. Татарстанны сайлап калганнар икән, без аларны сакларга, ашатырга тиеш.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

vk.com

САН

Татарстанда 30лап төр кош кыш чыга. Җылы якларга китмәүчеләрнең саны 2,5 меңнән артып китә.

Кәнфит түгел, дару

Кире уйларга соң түгел. Баласыннан котылырга карар кылган хатын-кызларга белгечләр шулай ди. Медикаментоз аборт вакытында дару эчеп өлгергән очракта да йөклелекне саклап калып, сау-сәламәт бала табып була, дип ышандыра алар. Шушы фикерне гүзәл затларга җентекләбрәк җиткерү өчен, Татарстанда «Передумала.ру» исемле проект эшли башлады.

Әлеге проектны башлап йөрүче табиб-психиатр, психолог Алексей Фокин сүзләренә караганда, бала тапканы өчен үкенгән хатын-кыз сирәк, ә менә бала төшерткән өчен үзен-үзе ашап яшәүче гүзәл затлар байтак, ди белгечләр. Проект әнә шундый аянычлы очракларны кисәтү өчен барлыкка килгән дә инде.

– Еш кына хатын-кыз кызган баштан шундый адымга баруына үкенә. Безгә килеп: «Иң зур гомерлек ялгыштан саклап калуыгыз өчен зур рәхмәт», – дип әйтүчеләр күп, – ди табиб.

Билгеле булганча, медикаментоз аборт вакытында 72 сәгать аерма белән ике дару эчәргә кирәк. Менә шуның беренчесеннән соң, кире уйлап, табиб билгеләгән тиешле даруны эчеп, йөклелекне саклап калып була. Татарстанның бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Ирина Волынец сүзләренә караганда, аборт ясатырга уйлаган хатын-кызларның 10–15 проценты, гадәттә, беренче төймәне капканнан соң кире уйлый икән. Шул рәвешле «Передумала.ру» проекты кысасында кулланылган алым махсус гормон ярдәмендә бала төшерү процессын туктатып калырга ярдәм итә. Белгечләр, әлеге гормон бала сәламәтлегенә зыян салмый, дип ышандыра.

– Дөрес, әлеге алым йөклелекне 100 процент саклап кала алачак, дип өздереп әйтеп булмый. Ник дигәндә, медикаментоз аборт вакытында эчелгән беренче дару баланы үтерү өчен уйлап табылган бик көчле агудан гыйбарәт. Тиз арада үз эшен башкарып өлгерергә дә мөмкин, – ди Алексей Фокин.

Әлеге проектта кулланылган алым турында фикер алышканда Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш репродуктологы Фирая Сабирова сүзләренә караганда, ничек кенә нәтиҗәле саналса да, абортны туктатучы гормон да – дару. Шуңа күрә аны табиб белән киңәшләшеп, белгеч күзәтүе астында гына кулланырга кирәк, дип кат-кат искәртте ул.

– Аны кулланганда, тискәре йогынтысы булып, кан китәргә дә мөмкин. Әнә шунысын да онытырга ярамый. Шуңа күрә бу даруны табиб күзәтүе астында гына эчәргә кирәк. Медикаментоз аборт вакытында эчелгән дару аналык эчендәге прогестерон гормонының рецепторларын томалый. Ул күбрәк рецепторны сафтан чыгарган саен, бала төшү ихтималы да арта бара. Аны туктату өчен билгеләнгән гормон исә шушы дару агуларга өлгермәгән рецепторлар өстенә урнашып, баланы саклап кала. Әгәр зарарланмаган рецепторлар бик аз калган булса, кан китәчәк. Күргәнегезчә, баш авырткан-да дару кабып кую гына түгел бу. Шуңа күрә дару ярдәмендә абортны туктатырга теләгән хатын-кыз, һичшиксез, табибка мөрәҗәгать итәргә тиеш, – дип кисәтә белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

✓Әлеге проект аша белгечләргә мөрәҗәгать итәргә теләгән хатын-кыз **+7 (928) 418-42-75** номеры буенча «кайнар элемтә»гә шалтырата ала.
✓Узган ел Татарстанда 12,5 мең бала төшерү очрагы теркәлгән. Шуларның яртысы хатын-кызның сәламәтлеге начар булу аркасында ясалган.

Аңлатабыз

КЕШЕСЕ БАР, ХУҖАСЫ ЮК


«ВТ» архивыннан

Бер танышым шалтырата: «Авылда бер өлкән яшьтәге туганыбызның бәләкәй генә өе бар. Ул аны инде әллә кайчан, яшь чагында ире белән бергә төзегән иде. Шул йортка документлар сорап килгәннәр. Эзләп караган, бернинди кәгазь дә тапмаган. Югыйсә гомер буена шунда яшәде инде ул. Нинди киңәш биреп карарга икән?» – ди.

Чыннан да, кайсы авылга барып чыкма, хуҗасыз йортлар шактый хәзер. Аларның барысын да ташландык дип тә әйтеп булмый. Хәтта күбесендә кешеләр дә яши. Буш торганнарының да варислары – ул-кызлары, оныклары бар. Ул йортны кайчандыр әби-бабалары төзегән һәм шунда гомер иткән, балалар үстергән. Шулай да, закон нигезендә рәсмиләштерелмәсә, йорт «хуҗасыз» булып саналырга мөмкин.

Бу очракта нишләргә? Рәсмиләштерүне нидән башларга? Росреестрның Татарстан идарәсе бүлек җитәкчесе Алсу Сафина әнә шул хакта аңлатма бирә.

– Беренче чиратта, әлбәттә инде, йортның теркәлгәнме-юкмы икәнен ачыклау мөһим. Бәлки, аның документлары гына югалгандыр. Ачыклау өчен Татарстан Республикасы Техник инвентарьлаштыру бюросыннан белешмә соратып алу мөһим. Чыннан да теркәлмәгән булса, эшкә тотына аласыз. Бу очракта «дача амнистиясе» дип аталган гадиләштерелгән ысулны эшкә җигәргә мөмкин. Тик бер шарт бар: моның өчен йорт салынган җир участогы милек буларак рәсмиләштерелгән булырга тиеш. Шушы таләп үтәлсә, техник план әзерләү өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә һәм, 350 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләп, исәпкә алу һәм теркәү өчен документларны күпфункцияле үзәккә илтеп бирәсе генә кала. Белешмәләр тәртиптә булганда, кадастр инженеры Росреестрга документларны үзе дә тапшыра ала. Моның өчен ышаныч язуы таләп ителми.

Әмма йорт төзелгән җир участогы турында да бернинди документлар булмаска мөмкин бит әле. Бу очракта участок урнашкан территориядәге җирле үзидарә органы архивына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр биләмәнең закон нигезендә беркайчан да беркемнеке булмавы ачыклана икән, ни кызганыч, алда әйтеп үтелгән гадиләштерелгән ысулдан файдаланып булмый. Сәбәбе: бу очракта йорт рөхсәтсез салынган дип санала, ягъни төзелеш өчен җир закон тәртибендә рәсмиләштерелмәгән булып чыга. Рөхсәтсез салынган йортка хокукны бары тик суд аша гына кайтарырга мөмкин. Шуннан соң инде тыныч күңел белән участокны рәсмиләштерү өчен җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәргә була.

Сезнең йортыгыз урнашуга карамастан, моңа кадәр дәүләтнеке яки муниципаль милек булып саналган җир участогын бушлай теркәү мөмкинлеге дә бар. Әгәр йорт билгеле бер торак пунктында даими яшәр өчен 1998 елның 14 маена кадәр төзелгән булса, сез бу хокуктан 2031 елның 1 мартына кадәр файдалана аласыз.

Хәзерге вакытта шушы уңайдан Россия Дәүләт Думасында закон проекты карала. Аның нигезендә, аерым алганда, түбәндәге үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Әгәр җирле хакимият органнары тарафыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә теге яки бу әйбернең хуҗасы табылмаса, аны «хуҗасыз» дип исәпкә алу өчен, вәкаләтле орган 14 көн эчендә Росреестрга гариза бирергә тиеш була. Бу – кемнең дә булса күчемсез объекты билгеле бер вакыттан соң муниципалитет милке була дигән сүз. Шуңа күрә Росреестрның Татарстан идарәсе күчемсез объектларны рәсмиләштерү эшенә игътибарлы булырга өнди. Исегезгә төшерәбез: теркәлгән очракта милекне сатарга да, бүләк итәргә дә, мошенниклардан сакларга да, дәүләт ихтыяҗларына кирәк булса, компенсация алырга да мөмкин булачак.

Росреестрның Татарстан буенча идарәсеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, бүген республикада 4,5 млн күчемсез объект бердәм дәүләт реестрына кертелгән. 847, 5 мең объектка хокук теркәлмәгән. Бу исемлектә 326,5 мең җир участогы, 195 мең торак бина, 112 мең торак йорт, 49 мең гараж, 49 мең бакча йорты, 3,6 мең төзелеш эшләре тәмамланмаган объект бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

АЗНАКАЙ ХИКМӘТЛӘРЕ

Карга күзен карга чукымый

Азнакай Сәпәендә туып, Бөгелмәдә яшәүче «Социалистик Татарстан»ның нефть төбәгендәге үзхәбәрче Дамир Асылов, 2000 еллар башында бездә иген уңышын гадәттән тыш саннарда күрсәтә башлагач, Азнакай газетасында авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкләүче буларак, миннән шуның чын серен таптыруга кереште.

– Әсгать, син бит беләсең инде аны, шуның эчендә кайныйсың, ничек ул гектардан күп дигән 20 центнер кинәттән 50 центнерга менә ала?

Өстәвенә әле ишеткән: «Сезнең башлыгыгыз үзенә рапорт бирүче председательләргә 40 центнердан күбрәк булса гына затлы коньяк каптырып чыгара икән». Асылов абзый һаман янымнан китми: «Син беләсең инде аны, яшерәсең – район күләмендә 50шәр центнер каян чыксын, аны кая куеп бетерәләр – амбарлары да санаулы гына бит. Ә нигә әнә Сарманда, Әлмәттә, Мөслимдә ипекәй центнерлары якын да килми? Безнең Бөгелмәне әйткән дә юк!» Ахыр чиктә җавап бирдем: «Дамир абый, минем монда яшисем бар, ярый син Бөгелмәдән киләсең дә китәсең!»

– Дөрес сүзләр, карга күзен карга чукымый. Бергә дус булып яшик. Ничек тә районны күтәрергә кирәк инде анысы! – диде Асылов, ниһаять, тынычланып.



Түгәрәк сан

Озак еллар «Маяк» район гәҗитенең авыл хуҗалыгы бүлеге җитәкчесе буларак, басмада чыккан һәр сан өчен җаваплы идем. Менә берчак мине шул бер сан өчен иртә белән авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы янына алып киттеләр.

– Нәрсә булды, Хәлим дус? – дим. – Әтиеңне – минем бик якын танышым, Рәсәйнең атказанган агрономы кадәр кешене – Хаҗимөгамбәр абыйны да болай олылап йөрткәннәре юк иде!

– Олылап түгел шул, – диде бу миңа бераз җикеренә төшеп. – Районны мәсхәрә итәргә ярамый, әнә «Маяк»та гектардан 24 центнер, дип җиппәргәнсез, мондый уңыш була димени?!

– Үзегезнең диспетчер журналына үзегез төшергән сан ич!

– Берәр түгәрәк сан юк идемени?

– Нинди сан соң ул?

– 40, 45, 48, 50 – болар сан түгелмени?

Шулай диюгә, телефоны шалтырады:

– Ало! Хәзер керәбез, ул минем кулда, Ильяс Җәүдәтович.

– Әйдә, шунда җавап бирерсең! – дип, мине начальнигы Латыйпов бүлмәсенә алып кереп, кызыл келәмгә бастырды.

– Теге вакыт булса, нишләтерләр иде?! Нигә районны артка тәгәрәтәсез? Гектардан 24 кенә нинди сан инде, түгәрәк сан беткәнмени?

– Нинди түгәрәк сан?

– 40, 45, 48, 50 – болар сан түгелмени?!

– Диспетчерыгыз журналына 24 дип баш агрономыгыз үз кулы белән төрткән бит!

– Аңа карасаң, барып чыгарсың, районны күтәрү өчен үзеңнең башың кайда?

– Бергәләп тырышырбыз, алайса, Ильяс Җәүдәтович, сезнең түгәрәк саннарны кулланып язарбыз яңадан.

– Хәлим, яңадан түгәрәк санны үзем куярмын, Казанга да шул китәр, син уралып йөрисе булма! – дип безне чыгарып җибәрде. Аннан чыкканда кызуы әле сүрелмәгән Хәлим куанып куйды: «Уф, авыр сан куюдан котылдым!» – диде һәм янәшәдәге кафега таба атлады.

Каләмеңне алдыртам

Заманында Никита Хрущев кебек шәхесләрне туган туфрагында каршы алган, ил күләмендә данлыклы «Авангард» колхозы председателе Миңнесәгыйрь абый Харрасов йомры сүзле, юморга бай кеше иде. Лаеклы ялга чыккач та, аны шул күркәм сыйфатлары өчен, районга килгән күренекле кешеләрне каршыларга иң алгы рәттә йөртәләр иде. Ләкин Миңнесәгыйрь абый үзләренең колхозына тигәнгә җене сөйми. Ә безгә, журналист-хәбәрчегә, гел караны ак дип кенә йөрергә туры килми: техника паркындагы, фермадагы кайбер җитешсезлекләрне гәҗитебез битендә күрсәткәләгәнбездер. Бер килүемдә ул тәмам һөҗүмгә күчмәсенме, чөнки узган атнада гына терлекчелектә районның халык контроле комитеты белән рейд ясап, җитди генә җитешсезлекләрне ачыклаган идек.

– Каләмеңне алдыртам мин синең!

Әлбәттә, аның кызудан әйтүе булгандыр. Газетада кимчелекләрне фаш иткән материаллар райком бюросы утырышына куелып тикшерелә һәм күпчелек очракта коммунист җитәкчегә шелтә биреп кайтарыла иде. Миңнесәгыйрь абыйның шундый «авыр» чагына туры килгәнмендер.

Ул аны күңелендә озак саклагандыр дип уйламыйм. Пенсиягә чыгып, юбилеена җиткәндә, ул редакциябезгә килеп керде.

– Каләмең озын гомерле булды, – диде ул, кырыема икенче урындыкны күчереп. – Бер-беребезгә хөрмәтле кешеләр булып калыйк!

Берничә көннән үзенең тыйнак кына сурәте белән чыккан язмама күңеленнән чыккан иң олы рәхмәтләрен әйтеп шалтыратты. Тымытык авылының ул чактагы тәүге ветераннар советы рәисе иде Миңнесәгыйрь абыебыз.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Аерылмагыз, аерылмагыз...



Чын бәхетнең нәрсә икәнен мин кияүгә чыккач кына аңладым. Әмма соң иде инде.

* * *

Беренче ир төерле була.

* * *

«Мин балага уздым, трубканы ал!» дигән асфальттагы язу тугыз катлы йортта яшәүче бөтен ирләрнең йокысын качырды.

* * *

– Кем алып кайтты сине?
– Такси.
– Ә нишләп үбешеп тордыгыз?
– «Комфорт» тарифы иде.

* * *

– Ирең шәп синең!
– Рәхмәт. Яңасы бу.

* * *

– Әйдә качышлы уйныйбыз? Син качасың, ә мин сине эзләмим.

* * *

Әгәр дә хатын-кыз сине чыгырыңнан чыгара алмый икән, димәк, бу сиңа язмыш тарафыннан бирелгән хатының түгел.

* * *

– Син мине бәхетле итәчәксеңме?
– Мин сине көчлерәк итәчәкмен.

Ләбиб ЛЕРОН

Кеме генә юк татарның...

Кеме генә юк татарның! –
Бар эт кебек өргәне,
Өсләреңнән таптый-таптый,
Изә-сыта йөргәне!

Кеме генә юк татарның –
Мәкерлесе, явызы:
Сине йотам, диеп тора
Кайберсенең авызы!

Кеме генә юк татарның –
Ялагае, куштаны:
Үлә-бетә үтәүчесе
Кемнәрнеңдер кушканын!

Кеме генә юк татарның –
Битарафы, җансызы...
Хәсетлесе, астыртыны,
Рәхимсезе, кансызы!

Кеме генә юк татарның –
Мәгънәсезе, мәнсезе...
Булдыксызы, вәгъдәсезе,
Әрсездән дә әрсезе!

Кеме генә юк татарның –
Кыйбласызы, динсезе...
Вөҗдансызы, намуссызы,
Имансызы, денсезе!

Кеме генә юк татарның –
Кыбырсыгы, мыжыгы...
Гадәтсезе, әдәпсезе,
Азгыны һәм бозыгы!

Кеме генә юк татарның...
Дәвам итсәң, күп тагы...
Сатлыкҗаны, мөртәте бар,
Шарлатаны, куркагы...

Татарымның, минем кебек,
Шундые да бар тагы:
Үзен гел әйбәткә санап
Шигырь язып ятканы!

Фотофакт

Әлеге фотосурәттә тарихи мизгел. 1967 ел. Футбол ярышы. Франция кубогы финалы. «Лион» һәм «Сошо» командалары ярыша. Стадионда меңәрләгән җанатар. Әмма туп, үч иткәндәй, хакимият вәкилләре һәм зур түрәләр утырган трибунага оча. Кем кулына диген әле! Франция Президенты Шарль де Голль тотып ала аны. Һәм кире футбол кырына ыргыта. «Бу илдә бөтен нәрсәне мин эшләргә тиеш икән!» – дип шаярып кычкыра Илбашы. Якын-тирәдәгеләр аның бу сүзләреннән шаркылдап көләләр.

Әз-мәз мәзәк

Телевизор сатып алмакчы идем, «черная пятница»лар бетсен инде, кыйммәткә аласы килми.

* * *

Гомерем буе көткән көнем килеп җитте: үтүгемне сүндердем микән, дип өйгә кире кергән идем, чыннан да сүндермәгәнмен икән!

* * *

Үз алдыңа зур максатлар куеп, аларны тормышка ашырып, үзеңне югарыга күтәрәсе килә дә бит, әмма бераз ятып та торасы килә.

* * *

Иренмә, диңгезгә барып кайт, ди миңа дусларым. Әйтерсең мине диңгездән бары тик иренү генә аерып тора.

* * *

– Димәк, сез безгә эшкә урнашмакчы буласыз. Үзегез турында сөйләгез әле?
– Сөйләүгә мин бик оста түгел. Мин бию әзерләдем.

* * *

Ирләрдә депрессия булмый, диләр. Алайса ни өчен алар иртәнге дүрттә 100 чакрым ераклыкка китеп, калкавычка карап утыра?

* * *

Тычканның кайсы җиренә укол ясама – ул барыбер «внутримышечный» булачак.

КВН һәм ШТКда ишеткәннәрдән

✓ Маляр апа эш көнен подъездда дивар буяудан башлаган иде. Шәмәхә урманда кызыл балыклар җыеп тәмамлады.

✓ Филолог бармагына чүкеч белән суккач, башта кемне-нәрсәне икәнен әйтә, аннары кемгә-нәрсәгә күчә.

✓ Күзе бик-бик яхшы күргән эт төннәрен Сатурнга улый.

✓ Кичә мантыйк буенча ярышта җиңүче җинде, аңа бүләк бүләк иттеләр.

✓ Тәҗрибәле фрезеровщик бармаклары белән вакланма саннарны күрсәтә ала.

✓ 8 яшьлек малайга би-ик озак карап торсаң, аңа 9 яшь тулачак.

✓ Электрикның тормышы шулкадәр күңелсез иде, ул баганадан егылып төшкәндә аның күз алдыннан 6 метр багана узды.

Фотобәтәч

Ниһаять, үземә таман шәмдәл таптым!

Мач әйткән!



Славомир МРОЖЕК, поляк язучысы

Иртәгә – шул ук бүген инде ул, әмма иртәгә.

БЕЛӘМ МИН

– Марат...
– Нәрсә, дәү әни?
– Марат, дим...
– Нәрсә инде?
– Өйләнергә кирәк сиңа.
– Кемгә?
– Кемгә дип... Үзең тап.
– Тапмадым бит әле.
– Вакыт бит инде.
– Очраклы кызны алып кайта алмыйм бит.
– Очраклы кызны алып кайт.
– Лилияне ярыймы?
– Юк, аларның гаиләсен беләм мин.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 375

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+